**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 9 августындагы 3331 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 9 августындагы 2615 номерлы**
**«Киров районы Осиново урамындагы җир кишәрлекләре**
**өлешләрендә ачык сервитут билгеләү турында»гы карары**
**гамәлдән чыккан дип тану турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанда юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе гаризасы нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 9 августындагы 2615 номерлы «Киров районы Осиново урамындагы җир кишәрлекләре өлешләрендә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**